**ФИНА паркы биләмәсенә алып керү тыелган әйберләр исемлеге**

***ФИНА паркы биләмәсенә түбәндәгеләрне алып керү тыела:***

1. Шартлаткыч матдәләр, алар тутырылган шартлату чаралары һәм предметлары.

2. Кысылган һәм сыекландырылган газлар, шул исәптән:

- Зажигалкалар,
- Буяу баллончыклары,
- Косметик спрейлар һәм макияж өчен буяулар.

3. Тиз кабынып китүчән матдәләр, шул исәптән шырпы.

4. Окисьлаучы матдәләр һәм органик перекисьлар.

5. Агулы матдәләр, радиоактив материаллар, зәһәр һәм коррозияләүче матдәләр.

6. Агулы һәм агулаучы матдәләр.

7. Теләсә кайсы төрдәге алкоголь продукциясе.

8. Наркотик һәм психотроп матдәләр, аларның прекурсорлары, шул исәптән дарулар рәвешендә (медицина документлары, табиб рецепты булган очракта рөхсәт ителә).

9. Корал һәм хәрби припаслар (утлы, сигнал бирүче, пневматик, газлы ату коралы, теләсә нинди хәрби припаслар, электр шогы җайланмалары һәм чаткы чыгаручы разрядниклар, утлы коралның төп өлешләре, корал рәвешендә кулланылырга мөмкин предметлар (биталар, таяклар һәм башка шундыйлар).

10. Корал рәвешендә кулланылырга мөмкин булган чәнчегеч һәм кискеч предметлар (маникюр кайчыларыннан гайре), пычаклар һәм бүтән салкын корал, атып тидерү предметлары, шул исәптән «трость» тибындагы.

11. 500 миллилитрдан артыграк савытларда сыеклыклар.

12. Пыяла контейнерлар, термослар, флягалар һәм шешәләр.

13. Сигаретлар, тәмәке тарту трубкалары, электрон сигаретлар.

14. Лазер белән сукырайткыч җайланмалар.

15. Радиоэлектрон җайланмалар (Чемпионат объектларында һәм алар янәшәсендәге районнарда чикләүләрсез кулланыла торган радиоэлектрон чаралар исемлегеннән гайре).

16. Теләсә нинди рәвештәге агитация материаллары, шулай ук флаглар һәм мәсхәрәле сүзләре һәм сәяси өндәмәләре, брендлар һәм коммерция продукциясе атамалары булган баннерлар. Милли җыелма команда флаглары искәрмә булып тора.

17. Тышкы яктан тыелган предметларны хәтерләтүче теләсә нинди предметлар яисә аларның күчермәләре һәм аналоглары.